| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Кучуковского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Көчек авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.03.2024 Түбән Көчек авылы № 42-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 31.01.2019 елның 44-1 номерлы Көчек авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив-хокукый актларны Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы, «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының " Көчек авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында" нигезләмәне раслау хакында" 31.01.2019 елның 44-1 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 29 бүлекнең 29.22 пунктында «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 9 бүлекнең 9.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә:

«12) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкетадагы мәгълүм үзгәрешләр турында аңа мәгълүм булган мәгълүматлар турында язма рәвештә хәбәр итәргә, моңа яллаучы (эш бирүче) вәкиленең карары буенча үзгәргән белешмәләр керми.»;

3) 11 бүлекнең 11.1 пунктындагы 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә һәм (яисә) аны узу чорында ялган документлар һәм (яисә) ялган белешмәләр кергәндә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрнең, тыюларның һәм таләпләрнең үтәлешен раслый торган чикләүләрне, тыюларны һәм (яисә) ялган белешмәләрне тапшырганда яки муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү турында таныклый торган документларны һәм (яисә) белешмәләрне тапшырмау;»;

4) 16 бүлекнең 16.3 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкетаны;»;

5) 16 бүлекнең 16.4 пунктында «белешмәләр» сүзеннән соң «(2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкетада булган белешмәләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлегенең мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru)

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы А.Р.Тухватуллина

Совет Кучуковского сельского поселения Көчек авыл җирлеге Советы ИНН 1601002526